## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

## ИСКЕ ИЛДЕРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

№ 5 21.03.2016 ел

Хөкем ителгәннәрнең җәзасын үтәү өчен мәҗбүри эш төрләрен һәм объектларны билгеләү турында

РФ Җинаять кодексы нигезендә 49 статьясының 1 өлеше, 25 статьясының 1 өлеше нигезендә. РФ Җинаять башкарма кодексының Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә хөкем ителгәннәр җәзасын үтәгәндә, шулай ук мәҗбүри эшләр рәвешендә җинаять җәзасы билгеләнгән затларны төзәтү, аларда җәмгыять нормаларына, кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә хөрмәтле мөнәсәбәт формалаштыру максатларында Иске Илдерәк авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРДЫ::

1. Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясе чикләрендә мәҗбүри эшләрне башкару урыннарын билгеләргә: Иске Илдерәк авылы, Яңа Илдерәк авылы, Тарханка авылы, Илешкино авылы һәм Чуваш Реторускино авылы җинаять – башкару инспекциясе белән килешү буенча.
2. Мәҗбүри эш төрләрен билгеләргә - торак пунктларны төзекләндерү һәм яшелләндерү, зиратларны төзекләндерү, юллар һәм буалар буендагы куакларны кисү, елгалар һәм чишмәләр территорияләрен санитар чистарту, җинаять-башкару инспекцияләре белән килешү буенча юлларны һәм башка тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлау.
3. Әлеге карарны Аксубай районы буенча ФКУ филиалы белән берлектә Россия Федераль җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять-башкару инспекциясе тарафыннан Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясендә яшәүче мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән затларга карата суд хөкемнәрен үтәүне тәэмин итү өчен җибәрергә.
4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштырырга: http:// aksubayevo.tatarstan.ru.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Илдерәк
авыл җирлеге башлыгы: В.К. Альметкин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОИЛДЕРЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ